Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге составына керүче
Олы Укмас авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

17 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 17 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Олы Укмас авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан,1 нче төркем инвалидлардан һәм өлешчә мобилизацияләүгә бәйле рәвештә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:
- Олы Укмас авылында зират коймасын тоту өчен материал сатып алу;
- Олы Укмас авылында евроконтейнерлар сатып алу.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 83 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 66 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 66 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Олы Укмас авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Олы Укмас авыл торак пунктларында тору

урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан һәм өлешчә мобилизацияләүгә бәйле рәвештә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Олы Укмас авылында зират коймасын тоту өчен материал сатып алу;
- Олы Укмас авылында евроконтейнерлар сатып алу.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шумково авылы,Үзәк урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Олы Укмас авылы, Үзәк урамы,42 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Хутор авылы, Яшьләр урамы, 5 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шумково авыл җирлеге Башлыгы Л.М.Назмиев